**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 18 » 04 2025 ел Яр Чаллы № 1279

«Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә премияләр бирү һәм матди ярдәм күрсәтү турында нигезләмәне раслау хакында»

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 22 апрелендәге 1473 номерлы карары, «Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтен оештыру һәм түләү шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 1473 номерлы карары (барлык үзгәрешләр белән) нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә премияләр бирү һәм матди ярдәм күрсәтү турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә премияләр бирү һәм матди ярдәм күрсәтү турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 02 апрелендәге 1026 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.С. Заһретдиновка йөклим.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 елның 18 04 1279 номерлы карарына кушымта

# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТ ҺӘМ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ҮЗӘГЕ» МБУ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНӘ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕНӘ ПРЕМИЯЛӘР БИРҮ ҺӘМ МАТДИ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә премияләр бирү һәм матди ярдәм күрсәтү турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 22 апрелендәге 1473 номерлы карары нигезендә эшләнде.

## 2. ПРЕМИЯ ТҮЛӘҮЛӘРЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕ

2.1. Хезмәткәрләргә айлык премия хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнә:

- «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ премия бирү турында нигезләмәгә 1 кушымта.

2.2. Премияләр район бюджетына керемнәрнең өстәмә чыганаклары булганда һәм хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә, һөнәри бәйрәмнәргә һәм бәйрәм көннәренә, эшләнгәнгән ай, квартал һәм ел йомгакларына карап (максималь күләм белән чикләнми), шулай ук югары эш нәтиҗәләре өчен (бер мәртәбә премия бирү) түләнергә мөмкин.

## 3. ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ ПРЕМИЯ БИРҮ

3.1. Хезмәткәрләргә премия бирү хезмәткә түләү фонды чикләрендә «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ башлыгы боерыгы нигезендә башкарыла.

3.2. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесенә премия бирү Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә хезмәткә түләү фонды чикләрендә башкарыла.

3.3. Премия бирү исемлекләренә хезмәткәрләрнең түбәндәге категорияләре кертелми:

- бала карау буенча ялда булган хезмәткәрләр.

## 4. ЭШЛӘНГӘН АЙ, КВАРТАЛ, ЕЛ ӨЧЕН ЭШ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА ПРЕМИЯ ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Әлеге бүлектә эшләнгән ай, квартал, ел өчен эш йомгаклары буенча премия түләү тәртибе һәм шартлары карала.

4.1.1. Эшләнгән ай, квартал, ел йомгаклары буенча бүләкләү хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфаларын вакытында һәм сыйфатлы башкаруда матди кызыксынуын арттыруга, шулай ук эшнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм аның сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән. Исәпләү һәм түләү һәр хезмәткәрнең хезмәтен индивидуаль бәяләү нигезендә башкарыла.

4.1.2. Премия хезмәт шартнамәләре буенча эшләүче һәм учреждениенең исемлек составындагы хезмәткәрләргә премия түләнә торган ай, квартал, ел ахыры торышы буенча бирелә.

4.1.3. Премияне исәпләү өчен нигез булып бухгалтерлык, статистик хисаплылык һәм оператив хисап, шулай ук фактта эшләнгән вакытны исәпкә алу мәгълүматлары тора. «Эшләнгән вакыт» төшенчәсенә хастаханә кәгазе чоры, административ ял керми.

4.1.4. Премия оешмада хисап календарь ай, квартал, елны эшләп бетергән хезмәткәрләргә эшләнгән вакытка пропорциональ исәпләнә.

4.1.5. Югары эш нәтиҗәләре өчен премия эш башкару йомгаклары буенча бер мәртәбә исәпләнә һәм түләнә.

4.1.6. Премияләр түбәндәге нигезләр буенча бүленергә һәм түләнергә тиеш:
- хезмәт һәм башкару дисциплинасын үтәү;
- хезмәт этикетын үтәү;
- коллективның һәм районның иҗтимагый тормышында катнашу;
- мөһим эшләрне башкаруда, чараларны оештыруда катнашу;
- хисапларны вакытында һәм тулысынча әзерләү.

## 5. ПРЕМИЯ КҮЛӘМЕН КИМЕТҮ ШАРТЛАРЫ ЯКИ АНЫ БИЛГЕЛӘҮДӘН БАШ ТАРТУ

5.1. Премия түбәндәге очракларда түләнми:
- хезмәт шартнамәсендә яисә вазыйфаи инструкцияләрдә каралган вазыйфаи бурычларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;
- җитәкче боерыклары һәм күрсәтмәләре белән билгеләнгән биремнәрне үтәү срокларын бозу;
- хасаплар дөрес булмау, бозу, фондлар һәм салым органнары буенча хисапларны һәм декларацияләрне тапшыру срокларын үтәмәү, штраф санкцияләренә юл кую;
- хезмәт дисциплинасын (соңга калган өчен премия бирмәү: 1 – 10%; 2-3 – 15%; 3 тапкырдан артыграк – 20%), эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре, башка локаль норматив актларны бозу;
- җитәкченең боерыкларын, күрсәтмәләрен һәм йөкләмәләрен үтәмәү;
- хезмәт күрсәтелә торган оешмаларның дәгъвалары, шикаятьләре булу;
- мөлкәтнең һәм товар-матди кыйммәтләрнең сакланышын тәэмин итмәү;

- дисциплинар түләтү һәм эштән азат итү өчен нигез буларак хезмәт законнарында билгеләнгән башка хокук бозуларны кылу.

5.2. Дисциплинар җәзасы булган хезмәткәрләргә премияләр түләнми.

5.3. Хезмәт дисциплинасын бозу булганда премиядән тулысынча яки өлешчә мәхрүм итү.

5.4. Премиядән мәхрүм итү турында карарны учреждение җитәкчесе кабул итә.

## 6. ӨСТӘМӘ МАТДИ ЯРДӘМ ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

6.1. Матди ярдәм гариза нигезендә түләнә:

- юбилей даталары (50 яшьтән башлап һәм аннан соңгы һәр 5 ел саен), никахлашу, бала туу (уллыкка алу, кызлыкка алу) уңаеннан 5000 сум күләмендә;
- катлаулы формада уза торган авыру очрагында бер вазыйфаи оклад күләмендә;
- якыннары (ата-аналары, балалары, ире (хатыны) вафат булган очракта, бер вазыйфаи оклад күләмендә;
- табигый бәла-каза яки гадәттән тыш хәлләр аркасында мөлкәтне югалту яисә зарарлану очрагында бер вазыйфаи оклад күләмендә.

Хезмәткәр вафат булган очракта, вафат булган кешенең бер акчалата тәэмин итү күләмендә матди ярдәм аның гаилә әгъзаларына яисә вафат булган көнгә аның тәрбиясендә булган затка аларның гаризалары буенча тиешле документлар күрсәтелгәндә түләнә.

Матди ярдәм түләү хезмәткә түләү фондында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## 7. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

7.1. Әлеге нигезләмә аны гамәлдән чыгарганчы, үзгәрткәнче яки яңасына алмаштырганчы гамәлдә була.